КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 декабрь г.Казань № 1201

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 октябрь, 741 нче; 2016 ел, 20 февраль, 104 нче; 2016 ел, 26 май, 354 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 832 нче; 2017 ел, 26 май, 311 нче; 2018 ел, 26 март, 174 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 763 нче; 2019 ел, 17 июнь, 495 нче; 2019 ел, 16 сентябрь, 837 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлында:

«58,2783» саннарын «58,9958» саннарына алыштырырга;

«8,7141» саннарын «9,4316» саннарына алыштырырга;

Программаның III бүлегендә:

«58,4783» саннарын «58,9958» саннарына алыштырырга;

«8,9141» саннарын «9,4316» саннарына алыштырырга;

Программага теркәлгән кушымтада:

4.18 нче пунктның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.18. Татарстан Республикасының мәгариф оешмаларында хокукый белемнәрне тарату максатларында белем бирү оешмаларының, фәнни-тикшерену оешмаларының профессор-укытучылар составы, белем бирү оешмаларының аспирантлары һәм студентлары арасында Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру темасына фәнни-гамәли тикшеренү эшләре конкурсын үткәрүне оештыру»;

4.19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «4.19. ТР мәгариф оешмаларында коррупциягә каршы юнәлешле конкурс үткәрү | Татарстан Республикасы МһФМ, ТР Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе (килешү буенча) | 2019 – 2022 еллар | ТР мәгариф оешмаларында үткәрелгән конкурслар саны | - | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - | 0,5175 | - | - | -»; |

«Программа буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән барлыгы» юлында «58,4783» саннарын «58,9958» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин